**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧУАШ БОРНАЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2015 елның 8 мае 14№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш Борнае авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

2002 елның 12 июнендәге "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы Сайлау кодексының 26 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш Борнае авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш Борнае авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны үткәрүнең бер мандатлы сайлау округлары схемасын (кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны «Әлки хәбәрләре» газетасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чуаш Борнае авыл җирлеге советы рәисе Зарипов И.Г. йөкләргә.

Чуаш Борнае авыл җирлеге Советы рәисе И.Г.Зарипов